# Эпидемиялəрдəн саклануга үн үгет-нəсыйхəт

إعداد

عبر الرزاق بن عبد المحسن البدر

غفر الله له ولوالديه

*Əзерлəде:*

Шəех Габдер-Раззакъ ибн Габдель-Мухсин əль-Бəдр

Барча мактау Аллаһка тиешле. Аллаһ Тәгалә генә дога кылучының догасына җавап бирә, кайгылы кеше Аннан ярдәм сорагандa аңарга ярдәм итә, барча начарлыктан һәм бәла-кәзалардан коткара. Калебләр Аллаһны зекер итеп кенә җанлана. Аллаһның рөхсәтеннән башка һичнәрсә дә була алмый. Аның рәхмәте һәм саклавы белән генә начарлыклардан котылабыз һәм сакланабыз. Аллаһтан килгән җиңеллек белән генә теләгәнебезгә ирешәбез һәм Аңа буйсынып кына бәхет эзлибез.

Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичкем дә юк, Аллаһ – Бер, һич тиңдәше юк дип шәһадәт бирәм. Ул – бердәнбер галәмнәр Раббысы, күкләрне һәм җирләрне тотып торучы, Аңа әүвәлге һәм ахыргы кавемнәр гыйбадәт кыла.

Ачык аңлатылган Китап һәм туры юл белән җибәрелгән Мөхәммәд пәйгамбәр – Аллаһның колы һәм рәсүле дип шәһадәт бирәм. Аңа һәм аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһтан мактау һәм сәлам булсын.

**Һәм аннан соң:**

Шушы арада “**коронавирус чире**” дип аталган эпидемия таралып кешеләрне хафага салуы сәбәпле, файдалы булган берничә нәсыйхәт бирәсем килә.

Һәм әлбәттә инде Аллаһтан безне һәм бөтен мөселманнарны барча начарлыклардан һәм бәла-казалардан коткаруын сорыйбыз. Аллаһ Тәгалә безне сакласын иде. Чөнки Аның гына моңа кодрәте җитә.

## 1. Бәла килгәнче әйтелә торган зекер

Госман ибн Гәффәннән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына: *мин Аллаһ илчесенең (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) сүзләрен ишеттем:* ***“Кем өч тапкыр: “Аллаһ исеме белән. Аның исеме белән җирдә дә һәм күктә дә һичнәрсә зыян китерә алмый, һәм Ул – Ишетүче, Белүче” дип әйтә - шуңа иртәнгә хатле кисәк кенә берниндиi дә бәла килмәс. Ә кем бу сүзләрне иртә белән өч тапкыр әйтә – шуңа кичкә хатле кисәк кенә берникнди дә бәла килмәс.”*** (Әбү Дәүд һ.б. риваяте)

بِسْمِ اللَّهِ الَّذِي لاَ يَضُرُّمَعَ اسْمِهِ شَيْءٌ فِي الأَرْضِ وَلاَ فِي السَّمَاءِ وَهُوَالسَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**[Бисмилләһи-ләзи лә йәдурру мәгьәсмиһи шәй’ун филь-әрдый үә лә фис-сәмә’и, үә һүәс-сәмиигьүль-гьәлиим]**

## 2. لَّا إِلَٰهَ إِلَّا أَنتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنتُ مِنَ الظَّالِمِينَ [Лә иләһә иллә әнтә, сүбхәнәкә, инни күнтү миназ-залимин] “[Йә, Аллаһ] Синнән башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичкем дә юк, Син һәр кимчелектән пакъ, мин үз-үземә золымлык кылдым” – дигән сүзләрне ешрак әйтү.

Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтә: **“Һәм кит карнында булучы Зүн-Нүнне [Юныс пәйгамбәр] искә ал: менә ул ачулы рәвештә китеп барды һәм Безнең аңа кодрәтебез җитмәс дип уйлады. Һәм ул караңгылыктан Безгә ялварды: “[Йә, Аллаһ] Синнән башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичкем дә юк, Син һәр кимчелектән пакъ, мин үз-үземә золымлык кылдым”. Без аңа җавап бирдек һәм хәсрәттән коткардык, менә шулай Без мөэминнәрне коткарабыз”.** (“Әль-әнбия” сүрәсе, 87-88 аятьләр).

Хәфиз ибн Кәсир Аллаһның “**менә шулай Без мөэминнәрне коткарабыз”** дигән сүзләре турында әйтте: *“Ягъни, мөэминнәргә бәла килсә – алар Аллаһка ялваралар һәм гөнаһларыннан гафу сорыйлар”.* Шуннан соң ул хәдис китерде, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Зүн-Нүннең [Юныс пәйгамбәр] кит карынына эләккәч кылган догасы:*** **“Лә иләһә иллә әнтә, сүбхәнәкә, инни күнтү миназ-залимин” “[Йә, Аллаһ] Синнән башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичкем дә юк, Син һәр кимчелектән пакъ, мин үз-үземә золымлык кылдым”,** ***мөселман кешесе шушы сүзләрне әйтеп Аллаһка нинди дә булса дога белән ялварса, Аллаһ аның догасына һичшиксез җавап бирәчәк”.*** (Имам Әхмәд, әт-Тирмизи риваятьләре).

Имам ибн аль-Къаййим үзенең “әль-Фәүәид” китабында әйткән: *“Кешегә бәла-каза килүне тәүхид (Бер Аллаһка гыйбадәт кылу) кебек башка берни дә этәрә алмый. Һәм бәла килгәндә укыла торган Юныс пәйгамбәр догасы тулысы белән тәүхидне үз эченә алган һәм Аллаһ Тәгалә тәүхид аша Юныс пәйгамбәрне коткарды. Ә кешене һәлакәт-хәсрәткә илтүче әйбер – ул ширек (Аллаһтан башкаларга гыйбадәт кылу – дога сорау һ.б.). Шуңа күрә кешене бу халәттән бары тик тәүхид кенә коткара ала. Ягъни тәүхид – кешенең котылу, сыену урыны, дивары. Ә тәуфикъ - Аллаһтан”.*

## 3. Аллаһтан авыр сынаулардан саклау сорау.

Әбү Һүрайра (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кыла: *“Аллаһ илчесе (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) авыр сынаулардан, авыр хәлдә калудан, начар язмыштан һәм дошманнарның явызлыгыннан Аллаһка еш дога кыла торган иде”*. (Әль-Бохари риваяте).

Шулай ук Әбү Һурайрадан (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Аллаһтан авыр сынаулардан, авыр хәлдә калудан, начар язмыштан һәм дошманнарның явызлыгыннан саклау сорагыз”.*** (Әль-Бохари риваяте).

**اللهمَّ إنِّي أعُوذُ بِكَ مِنْ جَهْدِ الْبَلَاءِ، وَدَرَكِ الشَّقَاءِ، وَسُوءِ الْقَضَاءِ، وَشَمَاتَةِ الْأَعْدَاءِ**

**[Әллаһүммә инни әгүзү бикә мин җәһдиль-бәлә’и, үә дәракиш-шәкъа’и, үә сү’иль-къада’и, үә шәмәәтәтиль-әгьдә’и]**

## 4. Өйдән чыкканда укыла торган доганы калдырмау:

## بِسْمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللهِ وَلَا حَوْلَ وَلَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللهِ

## [Бисмилләһи, тәүәккәлтү гьәлә-Аллаһи, үә лә хәүлә үә лә къуүәтә илләә билләһи]

Әнәс исемле сәхабәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Әгәр дә өйдән чыкканда мөселман кеше: “Аллаһ исеме белән, Аллаһка гына тәүәккәл кылдым, Аллаһтан башка беркемнән дә көч-куәт юк” дип әйтсә, аңа әйтелер ди: “Сиңа шушы җитә, син һидәяттән баручы, һәрбер начарлыктан һәм дошманнарның явызлыгыннан саклandың”. – Ә шәйтаннар бу кешене калдырырлар, һәм бер шәйтан икенчесенә әйтер ди: “Нәрсә эшли аласың син бу кеше белән, ул бит һидәяттән баручы, һәрбер начарлыктан һәм дошманнарының явызлыгыннан сакланган”.*** (Әбү Дәүд риваяте).

## 5. Иртән һәм кичен Аллаһтан иминлек сорау.

Габдуллаһ ибн Гомәр (Аллаһ алардан разый булсын) әйткән: *“Аллаһ илчесе (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) иртән һәм кичен шушы доганы укый иде:* ***“Йә Аллаһ, синнән дөнъяда һәм ахыйрәттә кимчелекләрдән имин кылуны сорыйм. Йә Аллаһ, синнән динемдә, дөнъямда, гаиләмдә һәм мал-мөлкәтемдә ярлыкауны һәм кимчелекләрдән имин кылуны сорыйм. Йә Аллаһ, минем гаурәтләремне капла һәм мине куркудан имин кыл. Йә Аллаһ, мине алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да һәм өстән дә сакла, мин Синең бөеклегеңә сыенамын хыянәтчел рәвештә астан үтерелүдән”.*** (Имам Әхмәд һ.б. риваяте).

**اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَافِيَةَ فِي الدُّنْيَا وَالآخِرَةِ، اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَفْوَ وَالْعَافِيَةَ فِي دِينِي وَدُنْيَايَ وَأَهْلِي وَمَالِي، اللَّهُمَّ اسْتُرْ عَوْرَاتِي، وآمِنْ رَوْعَاتِي، اللَّهُمَّ احْفَظْنِي مِنْ بينِ يَدَيَّ، ومِنْ خَلْفِي، وَعن يميني، وعن شِمالي، ومِن فَوْقِي، وأعُوذُ بِعَظَمَتِكَ أنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحتي**

**[Әллаһүммә инни әс-‘әлүкәл-гәәфиятә фид-дүнйә үәл-әәхыра, Әллаһүммә инни әс-‘әлүкәл-гәфүә үәл-гәәфиятә фи дини үә дүнйәйә үә әһли үә мәәли, Әллаһүммә-стүр гәүраати үә әәмин раугәәти, Әллаһүммә-хфазни мин бәйни йәдәййә үә мин халфи үә гьән йәмини үә гьән шимәәли үә мин фәукъый, үә әгьүзү бигьәзамәтикә ән үгътәәлә мин тәхти]**

## 6. Еш дога кылу.

Габдүллаһ ибн Гомәрдән (Аллаһ алардан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Дога ишекләре ачылган кешегә рәхмәт ишекләре ачылган. Ә Аллаһтан сорый торган әйберләрдән Аллаһ өчен иң ятраканы – иминлек сорау”.*** (әт-Тирмизи 3548. Хадис зәгыйфь. «Дагьиф әт-Тирмизи» 708, «Дагьифь әт-Тәргъиб» 1013. Ләкин аның мәгънәсен киләсе хәдис раслый).

**اللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْعَافِيَةَ فِي الدُّنْيَا وَالآخِرَةِ**

**[Әллаһүммә инни әс-‘әлүкәл-гәәфиятә фид-дүнйә үәл-әәхыра]**

***“Йә Аллаһ, синнән дөнъяда һәм ахыйрәттә кимчелекләрдән имин кылуны сорыйм”***

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Дога кылу - бәла килгәч тә, килгәнче дә файда китерә. Шуңа күрә күбрәк дога кылыгыз, йә Аллаһ коллары! ”.*** (Имам әт-Тирмизи һ.б. риваятьләре).

## 7. Чир таралган җирләрдән ераграк булу.

Габдүллаһ ибн Гәмирдән (Аллаһ алардан разый булсын) риваять кылына, бервакыт Гомәр ибн әль-Хаттаб (Аллаһ аннан разый булсын) Шәм территориясенә гаскәр белән юнәлде. Сәрга дип аталган урынга җиткәч, аңарга Шәмдә эпидемия таралуы турында җиткерделәр һәм ул тукталды. Һәм аңа Габдер-Рахмән ибн Гәүф пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) хәдисен сөйләде. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Әгәр дә сез берәр җирдә эпидемия таралуын ишетсәгез – анда бармагыз, ә әгәр дә эпидемия сез торган җирдә башланса – аннан, качарга теләп, чыкмагыз”.*** (Әль-Бохари һәм Мөслим риваятләре)

Әбү Һүрайрадан (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Авыру дөяләрне сәламәт дөяләр янына кертмәгез”.*** (Әль-Бохари һәм Мөслим риваятләре)

## 8. Саваплы гамәлләр кылу.

Әнәс исемле сәхабәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Саваплы гамәлләр кылу начар үлемне, афәтләрне һәм хәвеф-хәтәрләрне этәрә. Һәм бу дөнъяда саваплы гамәл кылучылар ахыйраттә дә шулар рәтеннән булырлар ”.*** (Әль-Хәким риваяте).

Имам ибн аль-Къаййим әйтте: *“Саваплы гамәлләр, кешеләргә яхшылык кылу, зекерләр, Аллаһка карата түбәнчел рәвештә еш догада булу, тәүбүгә килү - шифалану-савыгуга иң яхшы сәбәпләр булып торалар. Болар барысы да кешене чирләрдән ерагайта һәм авырту кешене савыгуга китерә. Бу сәбәпләр хәтта даруларга караганда да бөегрәк тәэсир бирәләр. Ләкин аларның тәэсире кешенең эчке халәтенә, аның шушы сәбәпләрне инанган хәлдә кабул итүенә һәм аларның файдасына ныклы ышануыннан тора”.* (“Зәду-ль-Мәгәд” китабы).

## 9. Төнге намазлар уку.

Биләл исемле сәхабәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять кылына, пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Төнге намазлар укыгыз, чөнки бу сезгә хатле яшәгән изге кешеләрнең гадәте иде. Төнге намазлар Аллаһка якынайта, начарлыктан тотып тора, гөнаһларны юк итә*** *[һәм тәннән чирләрне этәрә]****”.*** (әт-Тирмизи 3549. Хәдис «һәм тәннән чирләрне этәрә” дигән өлешеннән кала сахих булып тора. «Тәмәмүль-миннә» 244, «Әс-сильсилә әд-дагьифә» 5348, «Дагьиф әль-җәмигь» 3789).

## 10. Төнгә каршы ашау-эчү савытларын каплау.

Җәбир ибне Габдуллаһтан (Аллаһ алардан разый булсын) риваять кылына: *мин Аллаһ илчесенең (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) сүзләрен ишеттем:* ***“Ашау савытларын каплагыз, эчемлек савытларын бәйләгез. Чынлыкта ел дәверендә бер төн бар – ул төнне [җиргә] бер чир иңәр, һәм ул чир өсте капланмаган һәрбер ашау савытына һәм бәйләнмәгән һәрбер эчемлек савытына үтеп керер”.*** (Мөслим риваяте).

Имам ибн аль-Къаййим әйтте: *“Бу әйберне медицина фәне аңлата алмый”.* (“Зәду-ль-Мәгәд” китабы).

Һәм сүз ахырыннан искә төшерәсем килә – һәрбер мөселман кешесе Аллаһның рәхмәтенә өмет итеп, Аның әҗеренә омтылып, Бер Аллаһка тәвәккәл кылып, үзенең бөтен эшен һәм халәтен Аллаһ Тәгаләгә тапшырырга тиеш. Чынлыкта барча эшләр Аның Кулында, Аның рөхсәтендә һәм теләгендә.

Әгәр дә мөселман кешесен берәр нинди бәла тотса – ул күркәм сабырлык күрсәтеп моның әҗеренә омтылырга тиеш. Аллаһ Тәгалә сабыр булып, моның әҗеренә өмет иткән кешеләргә бик зур саваплар һәм яхшы нәтиҗә вәгъдә итте, Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтте: **“Чынлыкта, сабыр булучыларга аларның әҗерләрен исәпсез-хисапсыз бирербез”.** (“Әз-Зүмәр” сүрәсе, 10-нчы аять).

Бервакыт Гайшә (Аллаһ аңардан разый булсын) пәйгамбәребездән (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) чума авыруы турында сорау биргән һәм пәйгамбәребез (аңа Аллаһның мактауы һәм сәламе булсын) әйткән: ***“Ул Аллаһның кемгә тели шуңа җибәргән газабы һәм мөэминнәргә карата Аның рәхмәте. Әгәр дә Аллаһның колын чума авыруы тотса һәм ул сабырлык күрсәтеп үзе яшәгән җирдән чыкмаса, һәм үзе белән Аллаһның тәкъдирендә язылган гына булачагын исеннән чыгармаса, яу кырында вафат булган кеше әҗерен алачак”.*** (Әль-Бохари риваяте).

Һәм ахырдан, сорыйбыз Аллаһ Тәгалә безгә Үзе яраткан һәм риза булган саваплы гамәлләр кылуга, дөрес сүзләр сөйләүгә тәуфикъ бирсә иде. Ул – Аллаһ бары тик хакны гына әйтә һәм туры юлдан алып бара!

Барча мактау Бердәнбер булучы Аллаһка тиешле. Аллаһ Тәгаләдән безнең пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның гаиләсенә һәм сәхабәләренә мактау һәм сәлам булсын!